ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01 июля 2022 г. № 3307

Башкарма комитетның 2018 елның 25 сентябрендәге 5515 номерлы карары белән расланган муниципаль норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне һәм эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы муниципаль норматив хокукый актларга экспертиза үткәрү турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Законы, шәһәр Уставының 53 статьясы нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2018 елның 25 сентябрендәге 5515 номерлы карары (Башкарма комитетның 2019 елның 1 ноябрендәге 5655 номерлы, 2020 елның 11 декабрендәге 6789 номерлы, 2021 елның 2 апрелендәге 2286 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган муниципаль норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне һәм эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы муниципаль норматив хокукый актларга экспертиза үткәрү турында нигезләмәгә, 1, 2 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«1. Әлеге нигезләмә Башкарма комитет тарафыннан эшләнә торган һәм эшмәкәрлек һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектлары өчен мәҗбүри таләпләрне, инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен яңа бурычларны билгеләүче яки муниципаль норматив хокукый актларда элек каралган бурычларны үзгәртүче муниципаль норматив хокукый актлар проектларының (алга таба – актлар проектлары) җайга салу йогынтысын бәяләүне, шулай ук эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлеге мәсьәләләренә кагылышлы муниципаль норматив хокукый актларга (алга таба – норматив хокукый актлар) экспертиза үткәрү тәртибен билгели.

2. Актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра торган нигезләмәләрне ачыклау максатында үткәрелә:

1) эшмәкәрлек һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектлары өчен артык йөкләмәләр, тыюлар һәм чикләүләр кертү яки аларны барлыкка китерүгә булышлык итү;

2) эшмәкәрлек һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектларының, муниципаль берәмлек бюджетының нигезсез чыгымнарын барлыкка китерүгә булышлык итү.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Н.А. Кропотовага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов